УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасында инженерлык фәннәрен үстерү, инженерлык өлкәсендә күренекле фәнни хезмәтләре, фәнни ачышлары һәм уйлап табулары өчен галимнәрне бүләкләү һәм Андрей Николаевич Туполевның исемен мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Ике елга бер тапкыр бирелә торган Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне гамәлгә куярга.

2. Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитетын оештырырга.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты турында нигезләмәне (2 нче кушымта);

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты составын (3 нче кушымта);

«Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» дипломы тасвирламасын һәм бланк үрнәген (4 нче кушымта);

«Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» медале тасирламасын һәм сурәтен (5 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2015 елдан Татарстан Республикасы бюджетыннан өлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауга Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә акча күчерүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлеген раслау турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-651 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреш белән) расланган фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлегенә, түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«6. Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия.».

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 ел, 01 ноябрь
№ ПУ-1014

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «01» ноябрендәге
ПУ-1014 номерлы Указына
1 нче кушымта

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия турында нигезләмә

1. Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия (алга таба – Халыкара премия) Россия һәм чит ил галимнәрен инженерлык фәннәре өлкәсендә иң яхшы фәнни эшләре, фәнни ачышлары һәм уйлап табулары өчен бүләкләү һәм танылган авиаконструктор, СССР Фәннәр академиясе академигы Андрей Николаевич Туполевның исемен мәңгеләштерү максатларында гамәлгә куелды.

2. Халыкара премия, 2015 елдан башлап, ике елга бер тапкыр 10 ноябрьдә – А.Н. Туполевның туган көнендә Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә тапшырыла.

3. Халыкара премия Россиядән яки чит илләрдән бер галимгә аерым фәнни казанышлары, конструкторлык эшләре, шулай ук аларның җыелмасы өчен шәхсән тапшырыла.

4. Халыкара премиягә аерым авторларның бер тематикалы эшләре яисә эшләр комплексы тәкъдим ителә.

5. Халыкара премия авторның вафатыннан соң яки кабаттан тапшырылмый.

6. Халыкара премиягә лаек булган затларга «Инженерлык фәннәре өлкәсендә А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» дигән исем, диплом, медаль һәм Халыкара премияне гамәлгә кую турында указ басылып чыккан көн эквивалентында 5000 АКШ доллары күләмендә акча (Россия сумнарында) бирелә.

7. Халыкара премия бирү турында тәкъдимнәр дәүләт хакимияте органнары, Россия, чит ил фәнни оешмалары һәм халыкара фәнни оешмалар, югары белем бирү оешмалары һәм башка оешмалар тарафыннан Халыкара премия тапшырылачак елның 1 июненә кадәр Халыкара премия бирү комитеты (алга таба – Комитет) каравына тапшырыла.

8. Халыкара премияне тапшыруга кандидатлар Комитет тарафыннан аларның эшләре, ачышлары һәм уйлап табуларының фәнни һәм гамәли кыйммәтен исәпкә алып, сайлап алына.

9. Халыкара премия тапшыруга кандидатларны сайлап алу йомгаклары нигезендә Комитет Халыкара премия тапшырылачак елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Президенты каравына Халыкара премия тапшыру турында тәкъдим кертә.

10. Дипломны, медальне һәм акчаны Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән зат тапшыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «01» ноябрендәге
ПУ-1014номерлы Указына
2 нче кушымта

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты (алга таба – Комитет) Инженерлык фәннәре өлкәсендә А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне тапшыру буенча чаралар әзерләүне һәм уздыруны оештыру максатларында төзелде.

2. Комитет составы Татарстан Республикасы Президенты указы белән раслана.

3. Комитет составына дәүләт хакимияте органнары, Россия һәм чит ил югары белем бирү оешмалары, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләре кертелә.

4. Комитетка түбәндәгеләр йөкләнә:

а) инженерлык фәннәре өлкәсендә фәнни эшләрне, ачышларны һәм уйлап табуларны сайлап алу һәм карау;

б) Татарстан Республикасы Президентына Халыкара премия тапшыру турында тәкъдим кертү;

в) бүләкләү документларын рәсмиләштерү, диплом, медаль һәм акча тапшыруны оештыру;

г) Халыкара премия лауреатларының фәнни казанышларын таратуга булышлык итү.

5. Комитет сайлап алынган эшләрне рецензияләү һәм аларга экспертиза үткәрү өчен инженерлык фәннәре өлкәсе белгечләрен, шулай ук фәнни-тикшерену оешмаларын, югары белем бирү оешмаларын һәм башка оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.

6. Комитет әгъзалары үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында алып бара.

7. Комитет утырышлары, Комитет әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашкан очракта, гамәлгә хокуклы булып санала. Комитетның Татарстан Республикасы Президентына Халыкара премия тапшыру турында тәкъдим кертү карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән, Комитет әгъзаларының кимендә өчтән дүрте хуплап тавыш биргән очракта, Инженерлык фәннәре

өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия турында нигезләмәдә билгеләнгән вакыт эчендә кабул ителә.

Комитетның утырышта катнаша алмаган әгъзалары үз фикерләрен язмача рәвештә тапшыра һәм тавыш биргән вакытта алар исәпкә алына.

8. Комитетның барлык әгъзалары тавыш биргәнче Халыкара премиягә тәкъдим ителгән эшләр, тиешле рецензияләр һәм эксперт бәяләмәләре белән таныш булырга тиеш.

9. Комитет белән Комитет рәисе җитәкчелек итә, ул Комитет эшен планлаштыра, Комитет утырышларын билгели һәм алып бара. Комитет рәисе булмаган вакытта утырышларны аның урынбасары алып бара.

10. Утырышта тавыш бирү хокукы булган Комитет секретаре Комитет утырышларын әзерләү һәм үткәрү белән бәйле оештыру эшен һәм техник эшне башкара, шул исәптән Комитет каравына кертелгән документларны (мәгълүматларны) тикшерә, шулай ук Комитет карарларын рәсмиләштерә.

11. Комитет карарлары Комитет секретаре кул куя һәм рәис тарафыннан раслана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

12. Комитет эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «_01_» ноябрендәге
ПУ-1014номерлы Указына
3 нче кушымта

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты составы

Халиков Илдар Шәфкать улы	Татарстан Республикасы Премьер-министры, Комитет рәисе
Гыйльметдинов Альберт Харис улы	А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшерену техник университеты – КАИ ректоры, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча)
Гортышов Юрий Федорович	А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшерену техник университеты – КАИ президенты, Комитет секретаре (килешү буенча)
Баракос Джордж Николас	Ливерпуль университеты профессоры, Бөекбритания (килешү буенча)
Ван Чжи Цзинь	Нанкин аэронавтика һәм астронавтика университетының космонавтика факультеты деканы урынбасары, профессор, Кытай (килешү буенча)
Гапонцев Валентин Павлович	IPG Photonics Corporation директорлар советы рәисе һәм генераль директоры, АКШ (килешү буенча)
Зарипов Равил Хаммат улы	Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры

Пахомов Алексей Михайлович	«Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм эшкуарлар ассоциациясе» төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе генераль директоры (килешү буенча)
Савицких Николай Владимирович	«Туполев» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)
Сәлахов Мәкъзүм Хәлимулла улы	Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча)
Синяшин Олег Герольдович	Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге рәисе (килешү буенча)
Фәттахов Энгель Нәвап улы	Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры
Шмидт Михаэль	профессор, Фотон технологияләре институты директоры, Бавария Лазер Үзәге директоры, Фридрих-Александр исемендәге университет, Германия (килешү буенча)

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның « 01 » ноябрендәге
ПУ- 1014 номерлы Указына
4 нче кушымта

«Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» дипломы тасвирламасы һәм бланк үрнәге

«Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» дипломы бланкы тыгызлыгы 100 г/м^2 булган, 25% мамык жепселле, оптик агартусыз югары сыйфатлы кәгазьгә басыла.

Диплом бланкы А4 (210 мм × 297 мм) форматлы, вертикаль урнаштырылган кәгазь бите рәвешендә була, фоны ак төстә.

Бланкның сул өлешендә Times New Roman Italic шрифты белән, 14 п. кегльдә өч телдә – татар, рус һәм инглиз телләрендә:

«Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен
А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты
ДИПЛОМЫ
Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә
_____ елгы А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия
_____ биреллде».

Бланкның уң өлешендә «Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» медаленең алгы ягы һәм икенче ягы сурәтләнгән.

Язмадан һәм медаль сурәтеннән астарак өч телдә – татар, рус һәм инглиз телләрендә имза урнаштырылган, ул «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән, Татарстан Республикасы Президентының исеме инициалыннан, атасының исеме инициалыннан һәм фамилиясеннән тора.

Инженерлык фәннәре өлкәсендә
күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге
халыкара премия лауреаты

ДИПЛОМЫ

Татарстан Республикасы Президенты Указы
нигезендә _____ елгы А.Н. Туполев исемендәге халыкара
премиясе

_____ биреллде

*****

ДИПЛОМ

лауреата Международной премии
имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области
инженерных наук
Указом Президента Республики Татарстан
Международная премия имени А.Н. Туполева _____ года
присуждена

_____

*****

DIPLOMA

of the laureate of the A.N. Tupolev International Award
for outstanding contribution
in the field of Engineering Science
By the Decree of the President of the Republic of Tatarstan
the A.N. Tupolev International Award
of the year _____ is conferred to

_____

Татарстан Республикасы Президенты — *Р.Н. Миңнеханов*
Президент Республики Татарстан — *Р.Н. Минниханов*
President of the Republic of Tatarstan — *R.N. Minnikhanov*

_____

Татарстан Республикасы
Президентының
2014 елның «_01_» _ноябрендәге_
ПУ-1014 номерлы Указына
5 нче кушымта

«Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» медале тасвирламасы һәм сурәте

«Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» медале куе алтынсу төстәге металлдан коела һәм 42 мм диаметрлы түгәрәк формасында була.

Медальнең алгы ягында уртада академик А.Н. Туполев портреты төшерелгән.

Медальнең икенче ягында уртада – очып бара торган Ту-144 очкычының «текстура» сәнгать алымы (элементы) белән башкарылган ретушьланган сурәте.

Медальнең кырыйлары рельефлы чыгынты белән каймаланган. Медальнең бөтен сурәтләре рельефлы.

Медаль кызыл ефәк тасма белән тышланган дүртпочмаклы колодкага элмәк һәм бөҗра ярдәмендә беркетелә.

Медаль футлярга салынган.